**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«24» 05 2021 ел  Яр Чаллы  №1127

Дәүләт торак программалары (социаль наемнан тыш) буенча исәпкә куйганда һәм гражданнарга торак биргәндә торак мәйданы нормалары турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50 статьясын, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатында, торак урынының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына торак урынының гомуми мәйданы 18 кв. метрдан да ким булмаган күләмдә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәп нормасын билгеләргә.

2. Дәүләт торак программалары буенча гаиләнең бер әгъзасына 18 кв. метр күләмендә гомуми торак урыны мәйданы, әмма ялгыз яшәүче граждан өчен 33 кв. метрдан да ким булмаган гомуми торак урыны мәйданы һәм ике кешедән торган гаилә өчен 42 кв. метрдан да ким булмаган торак урыны мәйданы күләмендә торак урын бирү нормасын билгеләргә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү буенча урынбасары Р.С. Игътисамовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе  А. Р. Хәбибуллин